**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» июнь 2023ел. № 184

**“Әтнә муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Әтнә муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында" Әтнә район Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында.**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” , 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы “Коррупциягә каршы тору турында” федераль карарларына карата, Әтнә муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар кабул итте:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Әтнә район Советының “Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр турында белешмәләр бирү турында, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында” 2019 елның 15 ноябрендәге 177 номерлы карарын.

“Татарстан Республикасы Әтнә район Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында мәгълүмат бирү турында”2021 елның 28 июнендәге 54 номерлы Әтнә район Советы карарының 2 пунктын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының Җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе: Г.Г.Хәкимов